Яр Чаллы шәһәре
Башкарма комитеты Җитәкчесе
Ф. Ш. Салаховның
Шәһәр Советы
даими комиссияләренең
берләштерелгән утырышындагы
чыгышы
2022 елның 16 феврале
(13: 00 402 зал)

**Хөрмәтле Наил Гамбәрович!**
**Хөрмәтле депутатлар, чакырылган кунаклар!**

Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының 2021 елдагы эшчәнлеге турында сөйләргә рөхсәт итегез.

Пандемия белән бәйле катлаулы шартларга карамастан, Яр Чаллы шәһәре үзенең тотрыклы үсешен дәвам итә һәм җитештерү темпларын арттыра.

2021 елда, узган чор белән чагыштырганда, җитештерелгән сәнәгать продукциясе күләме **22 %** ка артты һәм **580 млрд. сум** тәшкил итте.

Шәһәр үсешен тәэмин итүче «КАМАЗ» предприятиесе К5 семьялыгы автомобильләрен базарга чыгару, газ-мотор техникасын үстерү, автобуслар һәм электробуслар булдыру эшен дәвам итә. Узган ел күрсәткечләре автогигант өчен соңгы **10** елда иң яхшысы булды: җитештерүнең үсеше **23%** тәшкил итте.

Шәһәр икътисадына башка эре сәнәгать предприятиеләре дә зур өлеш кертә. (Сез аларны экранда күрәсез).

**Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе** резидентлары тарафыннан 2021 елда шәһәр икътисадына **5 млрд. сум** акча кертелде, 484 эш урыны булдырылды.

Шәһәрнең икътисадый һәм социаль иминлеген характерлый торган мөһим аспект булып **кече һәм урта бизнес** тора, чөнки бу өлкәдә **54,5 мең** кеше хезмәт куя, ә шәхси эшмәкәрләргә ялланган хезмәткәрләрне дә исәпкә алганда, 87 меңгә якын кеше эшли (**86,9 мең кеше**).

Пандемия белән бәйле кыенлыкларга карамастан, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары бирешмәделәр, хәтта үсешләрен дә дәвам иттеләр.

Тулай территориаль продуктта эшмәкәрлек секторы **35 %** ны алып тора һәм шәһәр бюджетының **39%** ын формалаштыра. Үзмәшгульлекне исәпкә алып, кече һәм урта бизнес субъектларының гомуми саны 46 мең 665 берәмлекне тәшкил итә (*шуларның: 11513 – юридик затлар, 13576 – шәхси эшмәкәрләр, 21576 – үзмәшгульләр*).

Шунысы мөһим, елдан-ел икътисадның реаль секторында кече һәм урта эшмәкәрлекнең өлеше арта бара. Хәзер ул **25 %** дәрәҗәсенә җитте.

Шәһәр өчен мөһим бурыч булып **бюджет үтәлеше** тора.

2021 елда салым һәм салым булмаган керемнәрнең планлы билгеләнешен мобилизацияләүгә, бюджетның керем потенциалын үстерүгә һәм аның балансслылыгын үтәүгә аерым игътибар бирелде.

Шәһәр бюджетының керемнәре **13 млрд. сумга якын** (12 млрд. 905 млн. сум) тәшкил итте.

Башта расланган план билгеләнешләре үзкеремнәр буенча **25%** ка (1319 млн. сум) арттырып үтәлде. Керемнәрнең артуы физик затлар кеременә һәм мөлкәткә түләнгән салымнарның артуы белән бәйле.

Социаль-мәдәни өлкәне тәэмин итүгә 10 млрд.386 млн. сум акча юнәлдерелде.

«Милли икътисад», «Торак-коммуналь хуҗалык» һәм «Әйләнә-тирә мохитне саклау» тармакларын финанслау **1 млрд 519 млн. сум** тәшкил итте, бу 2020 елга караганда **427 млн. сумга** күбрәк.

**Автомобиль транспорты өлкәсендәге чараларга 331 млн. сум** акча тотылды, шул исәптән күп сыйдырышлы автобуслар сатып алуга – **234,5 млн.сум;** урам-юл челтәренә хезмәт күрсәтүче автомобильләргә капиталь ремонт ясауга – **5,8 млн. сум**.

**«Юл хуҗалыгы» бүлеге буенча** юлларны, тротуарларны кардан, тузаннан һәм пычрактан чистарту эшләрен башкаруга **503 млн. сум** финансланды (*2020 елда – 396 млн.)*.

**Шәһәр территориясен карап тотуга, яшелләндерүгә һәм төзекләндерүгә 169 млн. сум тотылды.**

**Урамнарны яктырту чыгымнары 158 млн. сум финансланды**, шуның **120 млн. сумы** урам утлары өчен электр энергиясе түләүгә җибәрелде.

**77** территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өчен 2021 елда **16 млн. сум** бүлеп бирелде. «Иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарә» конкурсы кысаларында җиңүчеләргә һәм призерларга **15 млн. сумлык** грантлар бирелде, алар микрорайоннарны төзекләндерүгә юнәлдерелде.

2021 елда **48/20** күпфатирлы торак йортында газ шартлауның нәтиҗәләрен бетерүгә шәһәрнең резерв фонды акчалары хисабына **42,5 млн сум** бүлеп бирелде. Моннан тыш, зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтү өчен счет ачылды. Хәйрия счетына шәһәр предприятиеләреннән һәм гражданнардан **1 млн 25 мең сум** акча керде. Әлеге фаҗигагә битараф калмаганнарга аерым рәхмәт әйтәсем килә. Берничә гаилә бер сәгать эчендә түбәсеннән, мөлкәтеннән, документларыннан колак какты. Кешеләргә үзвакытында ярдәм күрсәтелде. Барлык хезмәтләр дә оператив эшләде.

**Торак-коммуналь комплексны** карап тоту, ремонтлау һәм яңарту шәһәр хезмәтләреннән, предприятие һәм оешмалар ягыннан җитди игътибар таләп итә.

Әйтик, узган ел Яр Чаллыда **145** йорт ремонтланды, **99** лифт алмаштырылды. Чыгымнар суммасы **1 млрд. 473 млн. сум** тәшкил итте, шулардан **914 млн.сумы** – милекчеләр акчасы, **267 млн. сумы** – шәһәр бюджетыннан, **281 млн. сумы** республика бюджетыннан бүлеп бирелде.

2021 елның тагын бер төп проекты – «Безнең ишегалды». Узган ел **88** ишегалды төзекләндерелде. Квартал эчендәге юллар буенда **1725** парковка урыны барлыкка килде. **Җиде йөз берәмлек** (700) балалар җиһазы монтажланды. **1324** эскәмия, **1266** урна, **3595** яктырту баганалары, **667** ярымсфера урнаштырылды, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен **110** мәйданчык оештырылды. Шуны әйтәсем килә, әлеге программаны гамәлгә ашырганда, ишегалларны төзекләндерү проектлары кысаларыннан чыгып, без өстәмә парковка урыннары булдырабыз, мондый эш барлык шәһәрләрдә дә алып барылмый. Без мондый мөмкинлекләрне шәһәрдә яшәүчеләр өчен максималь уңайлы шартлар тудыру өчен эзлибез.

**Ике ел** эчендә барлыгы **219** ишегалды «яңа тормыш» башлый алды.

Әлеге программаны тормышка ашыруда шәһәрдәшләр дә актив катнаша. **Территориаль иҗтимагый үзидарәләр** рәисләре һәм активистлары аеруча инициатива күрсәтә.

Гражданнарның яшәешен тәэмин итү системасында **ягулык-энергетика комплексы** бик мөһим урынны алып тора. 2021 елда башкарылган эшләр күләме **2 млрд. 263 млн. сум** тәшкил итте. **«Яр Чаллы җылылык челтәрләре»** предприятиесе 20 км җылылык челтәрен тиешле дәрәҗәгә җиткерде. «ЧАЛЛЫ СУ КАНАЛЫ» **5,45 км** суүткәргечләргә һәм 1,47 км канализация челтәрләренә капиталь ремонт үткәрде. Шәһәр чикләрендә **15 км** (15,42) электр белән тәэмин итү челтәре торгызылды. Сидоровка поселогында – **297 м** суүткәргеч, Замелекесьеда **2,5 км** газүткәргеч салынды. Шәһәрнең төрле районнарында **1 836** яңа яктырткыч урнаштырылды.

Узган елның төп бурычы «КамгэсЗЯБ» объектларын «Татэнерго» җылылык челтәрләренә күчереп тоташтыру булды. Аны хәл итү өчен **мең ярым метрдан артык** (1520) җылылык челтәре салынды һәм реконструкцияләнде.

Халык өчен дә, шәһәр җитәкчелеге өчен дә хуҗасыз хайваннарга мөнәсәбәт, күзәтчелек итү әһәмиятле тема булып кала. Тукай һәм Яшел Үзән районнарында балаларга этләр һөҗүм иткәннән соң хәл бигрәк тә кискенләште. Узган ел «Шәһәр хуҗалыгы дирекциясе» муниципаль учреждениесе тарафыннан **1 495** баш хайван тотылды. Бу максатларга ТР бюджетыннан бүлеп бирелгән **9 млн. сум** күләмендәге субвенцияләр тулысынча үзләштерелде. Учреждение территориясендә **100** эткә исәпләнгән приют эшли.

Татарстан Хөкүмәте тарафыннан кабул ителгән кискен чаралар нәтиҗәсендә, республикада **3** приют төзеләчәк, шуларның берсе бездә – Яр Чаллыда. Бу максат өчен **16800 кв. м**. мәйданлы җир участогы билгеләнде. Объектны проектлауга техник йөкләмә ГИСУга җибәрелде.

**Юл хуҗалыгы турында берничә сүз.**

Яр Чаллы «Имин, сыйфатлы юллар» милли проектын тормышка ашыруда актив катнаша, аның кысаларында Шамил Усманов урамы буенча Халыклар дуслыгы проспектыннан Хәсән Туфан проспектына кадәр булган **1,5 км** озынлыктагы юлга капиталь ремонт ясалды. Әлеге участокта **350**

парковка урыны булдырылды, **205** юл билгесе, **10** ясалма юл тигезсезлеге һәм **45** тышкы яктырту баганалары урнаштырылды.

**«Юл-урам челтәрен ремонтлау»** республика программасы кысаларында Гостев урамы буенча, Аэродромная урамыннан алып Батенчук урамына кадәр күпер кичүе белән булган юлны реконструкцияләү башланды.

«Сосновая роща» һәм «Юбилейный» бакчачылык ширкәтләренә юллар ремонтланды.

**Юлларны ремонтлау нәтиҗәсендә, юл-транспорт һәлакәтләре күп булган 13 урын бетерелде**, **130**дан артык юл билгесе куелды, ясалма юл тигезсезлекләре ясалды, тавыш полосалары эшләнде.

35 мең кв. м мәйданда (34922,99 кв. м) **чокырларны ямау эшләре** башкарылды.

**Пассажирлар йөртү шулай ук мөһим мәсьәлә санала.**

Шәһәр маршрутларына көн саен **300**дән артык автобус һәм 70 трамвай чыга.

Узган ел шәһәр бюджетыннан «НЕФАЗ» маркалы 21 автобус сатып алуга акча бүлеп бирелде. Наил Гамбәр улының шәхси сөйләшүләр алып баруы нәтиҗәсендә, Мәскәү хөкүмәте тарафыннан тапшырылган автобуслар зур ярдәм булды.

Май аеннан октябрь аена кадәр ташламалы категориягә ия шәһәрдәшләребез өчен автобусларда 39 бакчачылык җәмгыятенә йөрү мөмкинлеге тудырылды. Шунысын да искәртик, безнең шәһәр – Татарстанда гражданнарны бакчаларга йөртүне субсидияләүче бердәнбер шәһәр. Узган ел бу максатларга шәһәр бюджетыннан **15 млн. сум** бүлеп бирелде.

Транспорт темасын дәвам итеп, Яр Чаллы – Россия шәһәрләре арасында **трамвай линияләре** үсеше алып барыла торган аз сандагы шәһәрләрнең берсе, дип билгеләп үтәм.

ЗЯБ поселогының Бумажники тукталышыннан алып Замелекесье аша ГЭС тагы Мәдәният паркына кадәр уза торган трамвай тармагын проектлауга шәһәр бюджетыннан **20 млн.сум** күләмендә акча бүлеп бирелде. Линиянең озынлыгы **13,5 км** тәшкил итә, **28 тукталыш** павильоны урнаштыру планлаштырыла. Елына 1,7 млн. пассажир булыр дип көтелә.

Торак-коммуналь хуҗалыгы тармагы эшчәнлегенең тагын бер мөһим юнәлеше – **шәһәрне яшелләндерү**.

Узган ел Сезнең белән бергә, хөрмәтле депутатлар, без **шәһәрне төзекләндерү**, агачлар һәм куаклар утырту буенча **актив шөгыльләндек**. Бер ел эчендә **25 мең** үсенте утыртылды, 6 га мәйданда 177 чәчәклек барлыкка килде. Шәһәр проспектларында лалә чәчәкләре генә дә 50 меңнән артык утыртылды.

Республика көне һәм Шәһәр көне алдыннан традицион чәчәкләр фестивале узды, ул Чаллы халкы һәм шәһәр кунаклары арасында зур популярлык казанды. Узган ел ул халык әкиятләре темасына багышланган иде.

**Яр Чаллы «Экология» милли проектын тормышка ашыруда актив катнаша.**

2021 елда Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы һәм Башкарма комитет арасындагы Килешү кысаларында табигатьне саклау чараларын үтәүне тәэмин итүгә шәһәр бюджетыннан **30 млн. сум** акча тотылды (*2020 елда – 29 960, 83 мең сум*). Акча шәһәр территориясен яшелләндерүгә һәм төзекләндерүгә, муниципаль карамактагы **3350 м** озынлыктагы участокта Мәләкәс елгасы үзәнен чистарту буенча проект-смета документлар эшләүгә юнәлдерелде.

Федераль карамакта булган Түбән Кама сусаклагычы зонасында **1450 м** озынлыктагы Мәләкәс елгасы үзәнен чистарту буенча шулай ук проект-смета документлары эшләнде. Әлеге участокны чистарту эшләре быел башланачак.

Өстәмә рәвештә шәһәр бюджетыннан Габдулла Тукай исемендәге яр буенда урнашкан ике локаль чистарту корылмасын проектлауга акча бүлеп бирелде.

**Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге эшебезнең нәтиҗәсе – «Эколидер» республика конкурсында 1 урынны яуладык.**

**Муниципалитет эшчәнлегенең тагын бер өстенлекле юнәлешләреннән берсе – төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тоту.**

2021 елда Башкарма комитетның вазыйфаи затлары тарафыннан административ хокук бозулар турында **20 меңгә** якын (**19 767**) беркетмә төзелде.

Административ комиссия **48 млн. сумнан** артык (*48 млн. 442 мең сум*) штраф салды.

Шәһәр бюджеты хисабына **3 млн. сумлык** «Дозор» программа-аппарат комплекслары сатып алынды, алар яшелләндерелгән территорияләрдә, балалар һәм хуҗалык мәйданчыкларында парковкалау буенча хокук бозуларны автомат режимда теркәп бара. Шуның нәтиҗәсендә, административ комиссия тарафыннан **11 мең** карар чыгарылган (*10 899*), салынган штрафлар суммасы **31 млн.684 мең сум** тәшкил итә. Чагыштыру өчен – 2020 елда **3 мең** беркетмә төзелгән, штрафлар суммасы якынча **5 млн. сум** (4 млн. 845 мең сум) тәшкил итте.

**Тагын шунысын да билгеләп үтәсем килә, узган ел санкцияләнмәгән сәүдә һәм алкогольле продукциянең законсыз әйләнешен булдырмау мәсьәләләренә зур игътибар бирелде.**

Санкцияләнмәгән сәүдәгә каршы тору максатларында шәһәрнең барлык 3 районында да эшче төркемнәр оештырылды, алар атна саен рейдлар үткәрделәр. Нәтиҗәдә, **5 меңнән** артык беркетмә төзелде (5041), **9 млн. сумлык** штраф салынды.

Алкогольле продукциянең законсыз әйләнешен кисәтү буенча **199** рейд үткәрелде, алар барышында закон таләпләрен бозуның **55** очрагы ачыкланды. Шәһәр ведомствоара комиссиясенең **12** утырышы үткәрелде, утырышларга аларның сәүдә нокталарында спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә хокук бозулар ачыкланган **30** дан артык эшмәкәр чакырылды.

Легаль булмаган хәмер сатуга каршы уртак максатчан көрәш республика дәрәҗәсендә билгеләп үтелде – **Яр Чаллы шәһәре җиденче ел рәттән 1 нче урынны алды.**

Шәһәрнең **муниципаль милек һәм җир ресурслары белән идарә итүнең максималь нәтиҗәлелеген** тәэмин итү – Башкарма комитет эшчәнлегендә мөһим юнәлешләрнең берсе.

2021 елда шәһәр бюджетына **1 млрд. 121 млн. сум** акча керде, бу 2020 елга караганда **338 млн.сумга** артыграк.

**24 млн. сумга** муниципаль милек объектлары гамәлгә ашырылды. Муниципаль милекне арендалаудан **70 млн. сум** күләмендә акча алынды.

Җир участокларын сатудан шәһәр бюджетына **270 млн. сум** керде, бу план күрсәткеченнән **91 млн. сумга** артып китә.

2021 елда шәһәр бюджетына җир өчен аренда түләвеннән фактта кергән акча **688 млн. сумны** тәшкил итте.

Хәзерге вакытта стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру хокукын алуга **172** шартнамә һәм реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә **424** шартнамә гамәлдә. Гомуми керем **83 млн. сум.**

Яхшы мисал китерәсем килә. 2021 елның сентябрендә **9 медиаэкран** урнаштыру хокукына сатулар үткәрелде. Шартнамәнең башлангыч бәясе **2 млн.сум** тәшкил иткән булса, сату нәтиҗәләре буенча ул **33 млн. сумга** җитте. Якын арада тагын **15 медиаэкран** урнаштыру өчен сатулар үткәрү планлаштырыла.

АТИ идарәсенең җирдән файдалануны һәм яшел утыртмаларның сакланышын контрольдә тоту бүлеге тарафыннан узган елда **1700 ләп күчмә тикшерү** үткәрелде.

Җир законнарын бозуның **106** очрагы ачыкланды, шуның нәтиҗәсендә, аренда түләүләре **15 млн. сумга** (14 971 785) җиткерелде.

Шәһәр икътисадының мөһим өлешләреннән берсе – төзелеш тармагы.

Ел нәтиҗәләре буенча төзү-монтаж эшләре күләме **20 млрд.сум** тәшкил итте (*2019 елда – 22,1 млрд. сум, 2020 елда – 19,4 млрд. сум*).

Шәһәрдә сәнәгать объектлары, инвестицион торак төзелде, социаль әһәмияткә ия объектлар төзелде һәм капиталь ремонтланды. Бер ел эчендә төзелешкә **396** рөхсәт һәм объектларны файдалануга тапшыруга **208** рөхсәт бирелде.

**Икътисадның иң әһәмиятле өлкәләреннән берсе булып торак төзелеше тора.**

2021 елда **322 мең кв. м** торак файдалануга тапшырылды.

Торакка ихтыяҗ саклана. Статистика мәгълүматлары буенча 2021 елда Яр Чаллы шәһәренең бер кешесенә торак белән тәэмин ителеш – 24,5 кв.м (*республика буенча – 28 кв.м) (2020 елда – 24,1 кв. м, ТР буенча тәэмин ителеш – 27,5 кв. м*).

**Социаль ипотека буенча торак төзелеше программасы өстенлекле бурыч санала.** 2021 ел башына **1332** гаилә социаль ипотека буенча фатир алу чиратында торды.

«Социаль ипотека» программасы буенча төзелгән **63/20** һәм **63/21** күпфатирлы ике торак йорт **823** гаиләгә торак шартларын яхшыртырга мөмкинлек бирде.

2020 елның 1 июленнән социаль ипотека буенча торак алу мөмкинлеге барлык яшь гаиләләргә, шул исәптән коммерция, бюджеттан тыш оешмаларда һәм предприятиеләрдә эшләүче, шулай ук шәхси эшмәкәрләргә һәм үзмәшгульләргә бирелә.

Безнең шәһәрдә әлеге мөмкинлектән **274** гаилә файдаланды, шуларның **86** сы инде төзелгән йортлардан торак алды.

Яр Чаллы шәһәре 2021 елда социаль объектларны төзү һәм капиталь ремонтлау буенча **8 миллиард сумлык 12 федераль һәм республика программаларында** катнашты.

* Без **2 мәктәп, 3 балалар бакчасы** төзедек.

* **5 мәктәп** ремонтланды, алар янәшәсендәге территорияләрне төзекләндерү өстәмә башкарылды.

* 10 мәктәптә **азык-төлек блогы** ремонтланды.

* **2 мәктәп территориясендә** ясалма өслекле минифутбол кырлары төзелде.

* **2 балалар бакчасы** ремонтланды.

* Яңадан профильләштерү хисабына **14 балалар бакчасында ясле төркемнәре булдырылды.**

* «Дулкын» бассейнын ремонтлау төгәлләнде.

* Йогышлы авырулар хастаханәсенең **«Б» блогына** капиталь ремонт ясалды.

* Гренада паркын төзекләндерү эшләре тәмамланды.

* Яшь Ленинчылар бульварына ремонт ясалды.

* «Мастеровые» рус драма театры төзелеше дәвам итә.

* «Чишмә» халыклар дуслыгы йортына капиталь ремонт башланды.

Казан шәһәренең 175 номерлы гимназиясендә булган фаҗигале вакыйгалардан соң, террорчылыкка каршы куркынычсызлык чаралары кысаларында, шәһәр бюджеты акчалары хисабына:

* **108 учреждениедә 18 млн. сумлык** өстәмә видеокамералар урнаштырылды.

* **153 учреждениедә 27 млн. сумлык** тавышлы хәбәр иткечләр урнаштырылды.

* **42 учреждение** территориясендә **165 млн. сумга** коймалар алыштырылды.

**Социаль өлкә турында берничә сүз.**

Сәламәтлек саклау оешмаларының эше узган ел коронавирус инфекциясе булган пациентларга медицина ярдәме күрсәтүгә юнәлдерелгән

иде. Авыруларны дәвалау өчен **өч** стационар *(«2 нче шәһәр хастаханәсе» ДАССУ, «5 нче шәһәр хастаханәсе» ДАССУ, «Сугыш ветераннары госпитале» ДАССУның профильләре үзгәртеп корылды, «Ашыгыч медицина хастаханәсе»* базасында йогышлы авырулар өчен койкалар куелды.

Объектив кыенлыкларга карамастан, медицина хезмәткәрләре тарафыннан өлкән яшьтәге **86 меңгә якын кешегә** диспансерлаштыру үткәрелгән.

Иң мөһим бурычларның берсе вакциналаштыру булды.

Шәһәрнең дәвалау-профилактика учреждениеләрендә табиблар белән тәэмин ителеш **59,6%** тәшкил итә (*2021 елның 1 гыйнварына – 59,0%).* Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантын (ул **800 мең сум** күләмендә) бирү программасы кысаларында табибларны җәлеп итү буенча эш дәвам итә.

2021 елда килгән барлык табиблар шәһәр бюджетыннан **200 мең сум** күләмендә бер тапкыр бирелә торган акча да алдылар. Нәтиҗәдә, гомуми сумма 1 млн. сум тәшкил итте.

**Халыкны социаль яклау** системасы тарафыннан кирәкле хезмәтләр һәм гарантияле ярдәм чаралары күрсәтелә.

Яр Чаллыда төрле төрдәге пенсия алучы **149 мең** кеше яши.

2021 елда төрле дәрәҗәдәге бюджетлардан түләүләрнең гомуми суммасы **2 млрд 540 млн сум** тәшкил иткән.

**Мәгариф**

2021/2022 уку елында шәһәрдә **131** мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе эшли, аларга **33 565** бала йөри (*2020/2021 – 34 165 бала*).

Моннан тыш, бездә **80** гомуми белем бирү учреждениесе эшли, аларда **68 380** бала укый (*2020/2021 уку елында – 65 298*).

**Бердәм дәүләт имтиханы** нәтиҗәләре буенча барлык фәннәр буенча уртача балл республика һәм Россия күрсәткечләреннән югарырак.

**34** чыгарылыш сыйныф укучысы **100 балл** алды (*2020 – 43*): *рус теле – 10, математика – 3, химия – 7, әдәбият – 3, җәмгыять белеме – 2 тарих – 4, информатика – 5.*

**Ике** чыгарылыш сыйныф укучысы **йөзәр** баллы нәтиҗә алды. *(Алар – 57 нче гимназияне һәм 78 нче лицейны тәмамлаучылар (2020 елда 26 нчы гимназиядән дүрт чыгарылыш сыйныф укучысы);*

**248** чыгарылыш сыйныф укучысы (*2020 елда – 235 чыгарылыш сыйныф укучысы*) Россия Федерациясенең «Укудагы аерым уңышлары өчен» медале белән бүләкләнде.

**Спорт**

Шәһәрдә физик культура һәм спортны үстерү буенча системалы эш алып барыла. Физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүчеләр **50,7%** тәшкил итә (*2020 елга караганда 1 % ка күбрәк*).

2021 елда Яр Чаллы спортчылары бөтенроссия һәм халыкара ярышларда уңышлы чыгыш ясадылар.

Яшьләр арасында чаңгы ярышлары буенча **Дөнья чемпионатында** Сергей Ардашев көмеш һәм бронза медальләр яулады. **Ришат Исхаков** билбау көрәше буенча дөнья чемпионы булды. **Кирилл Козлов** – батутта сикерү буенча Европа беренчелегенең бронза призеры, **Нияз Билалов** дзюдо буенча «Гранд Шлем» халыкара ярышларында җиңүче булды. **Зөлфәт Гәрәев** авыр атлетика буенча **Европа чемпионатында** көмеш, ә дөнья чемпионатында бронза медаль яулады. **Анна Казарновская** тхэквондо буенча **Дөнья чемпионатының** көмеш призеры булды. «КАМАЗ» футбол клубы ПФЛ клублары командалары арасында футбол буенча **Россия беренчелегендә** җиңүче булды.

**Яшьләр сәясәте**

Яр Чаллы яшьләре спортта гына яхшы нәтиҗәләр күрсәтеп калмыйлар. Безнең егетләр яшьләр сәясәте линиясе буенча бөтенроссия, республика һәм шәһәр чараларында җиңүчеләр һәм призерлар булалар. 2021 елда шәһәргә **7 млн. сумлык 94 грант** җәлеп ителгән.

Коронавирус пандемиясе чорында волонтерларның эшчәнлеге аеруча да актуаль һәм әһәмиятле. Шәһәрдә **13 385** кешене берләштергән 100 волонтерлык һәм иҗтимагый оешма эшли. Ведомствоара үзара эшчәнлекне оештыру һәм сыйфатлы эш алып бару максатларында, 2021 елда ел саен **500 мең сум** күләмендә финанслау белән ирекләләр үсеше буенча **муниципаль программа кабул ителде.**

**1 253** балага ял итү һәм сәламәтләндерү чаралары оештырылган, шуларның **468** е – авыр тормыш хәлендә калган балалар.

**Башкарма комитет хәл итә торган җаваплы бурычларның берсе – Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына чакыру планын үтәү.**

2021 елда **603** яшь кеше хәрби хезмәткә озатылды. Аларның 362се (60% чамасы) шефлыкка алынган хәрби частьларга җибәрелде. Язгы һәм көзге чакырылыш йөкләмәсе тулы күләмдә үтәлде.

**Мәдәният**

2021 ел Яр Чаллы шәһәре мәдәният учреждениеләре өчен **Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы** кысаларында узды.

Россиянең кече шәһәрләре театрлары фестивален уздыру безнең шәһәр өчен ел вакыйгасы булды, анда илебезнең төрле төбәкләреннән **16** иҗат коллективы катнашты.

Фестиваль нәтиҗәләре буенча Яр Чаллының «Мастеровые» рус драма театры актеры **Евгений Гладких** «Иң яхшы ир-ат роле» өчен бүләкләнде.

Икенче ел рәттән мәдәният учреждениеләре чикләүләр шартларында эшли. Шуңа да карамастан, шәһәр паркларында һәм җәмәгать киңлекләрендә **230** чара үткәрелде.

Сәнгать уку йортларында тәрбияләнүчеләр шәһәргә һәм республикага республика, бөтенроссия һәм халыкара дәрәҗәдәге конкурсларда катнашып, **ике меңгә** якын җиңү китерде.

**11** учреждение 7 млн. сумлык (*6,8 млн. сум*) грантка ия булды.

Шәһәр **«Пушкин картасы»** федераль программасына актив кушылды. 2021 елда әлеге карта акчасына **8 млн сумнан** (*8 226 635 сум*) артык бәягә **15 537** билет сатылган.

**Җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү буенча җаваплы функция Башкарма комитетның тиешле идарәсенә йөкләнгән.**

Башкарма комитет һәм шәһәрнең барлык хокук саклау хезмәтләренең уртак эшчәнлеге нәтиҗәсендә 2021 елда җинаятьчелекнең гомуми дәрәҗәсе 4,6% ка (*2020 елдагы 7777 дән 2021 елда 7417 гә кадәр*) кимеде. Шәһәрнең җәмәгать урыннарындагы җинаятьләр саны 7,5 % ка, урам җинаятьчелеге 14,7 % ка, яшүсмерләр арасындагы җинаятьчелек 49% ка кимеде.

Башкарма комитетның җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү идарәсе шәһәр, республика һәм федераль әһәмияткә ия булган барлык массакүләм мәдәни-тамаша һәм спорт чараларын үткәргәндә полициягә ярдәм күрсәтте. «Җиңү көне», «Соңгы кыңгырау», «Сабантуй», «Яшьләр көне» һәм башка шундый чараларны үткәргәндә хокук тәртибе һәм иминлек тиешле дәрәҗәдә сакланды.

Җәмәгать куркынычсызлыгы чараларын үтәү өчен шартлар тудыру максатыннан **«Имин шәһәр» АПКсы** өчен программа тәэминатын яңарту буенча эш башкарылды. Шәһәр бюджеты акчасына тормышка ашырыла торган яңа программа видеокүзәтү камераларын домофон аша кулланырга һәм булган камераларны нәтиҗәлерәк файдаланырга мөмкинлек бирәчәк. «Имин шәһәр» комплексында барлыгы **2815** видеокүзәтү камерасы эшли, шуларның **369**ы узган ел тоташтырылды.

2021 елда «Таттелеком» ААҖ белән сөйләшүләр барышында **иске аналоглы домофоннарны яңа IP домофоннарга алыштыру** буенча үзара эшчәнлек турында килешүгә ирешелде.

IP домофоннар видеокүзәтү камералары белән җиһазландырылган, аларны «Имин шәһәр» АПК серверларына тоташтырырга мөмкин.

Ел башына булган мәгълүматларга караганда, Таттелеком тарафыннан **70** IP домофон урнаштырылды;

2022 елда **4 000** IP домофон урнаштыру планлаштырыла, 2023 елда – **3000.**

Домофоннарны модернизацияләгәндә «Домофон» хезмәте бәясе шәһәр халкы өчен торак-коммуналь хезмәтләрне исәпләгәндә үзгәрмәячәк.

**Гражданнарның конституцион хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең мөһим юнәлеше булып гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тора.**

2021 елда җирле үзидарә органнары тарафыннан **тугыз меңгә** якын мөрәҗәгать каралды.

Гражданнарның хакимият органнарына мөрәҗәгать итүенең иң кулай һәм традицион формасы – **язмача мөрәҗәгатьләр**. 2021 елда барлыгы **5475** язма мөрәҗәгать керде (*2020 – **6025***).

**Шәхси кабул итү** шулай ук гражданнарның хакимият органнары белән элемтә формасы булып кала бирә.

2021 елда **3 458** чаллылы нәкъ менә шушы формадан файдаланды, Башкарма комитетның структур бүлекчәләре җитәкчеләренә мөрәҗәгать итеп, шәхси кабул итүдә булды, шул исәптән мин шәхсән **170 кешене** кабул иттем.

Татарстан Республикасының **«Халык контроле»** дәүләт мәгълүмат системасы гражданнарның хакимият органнарына мөрәҗәгать итүенең тагын бер формасы булып санала. Халык бу ресурстан елдан-ел активрак файдалана.

2021 елда Яр Чаллы халкы тарафыннан 10139 гариза бирелгән, бу 2020 елга караганда 2295 гаризага күбрәк (*2020 елда – 7844*). 2021 елда кергән гаризаларда бәян ителгән мәсьәләләрнең **86,4%** ы хәл ителгән.

Узып киткән ел ил тарихына **Бөтенроссия халык санын алу** елы буларак кереп калачак. Бу – Россиянең хәзерге тарихында өченче халык санын алу. Яр Чаллы бу масштаблы акциядә актив катнашты.

**Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатларын сайлау** дәүләт дәрәҗәсендәге тагын бер вакыйга булды. Чаллылылар, һәрвакыттагыча, гражданлык бурычларын югары дәрәҗәдә үтәделәр. Сайлауларда 80% ка якын халык катнашты.

**Хөрмәтле депутатлар!**

Яңа коронавирус инфекциясе белән бәйле катлаулы шартларга карамастан, узган ел безнең шәһәр яшәде, эшләде, мөһим социаль проектларны тормышка ашырды. Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы җитәкчелеге белән бергә без пандемиянең шәһәр икътисадына йогынтысын киметү өчен күп көч куйдык. Федераль, республика һәм муниципаль программалар буенча барлык йөкләмәләрне үтәү әлеге максатчан эшнең нәтиҗәсе булды.

**Безнең алда 2022 елга да мөһим бурычлар тора:**

* **330 мең кв. м** торакны файдалануга тапшыру планлаштырыла.

* **129 күпфатирлы йортка** капиталь ремонт ясалачак.

* «Безнең ишегалды» программасын тормышка ашыру кысаларында **119 ишегалды территориясе** төзекләндереләчәк.

* **69 нчы микрорайонда 1501 урынга исәпләнгән мәктәп төзелеше** башланды.

* **Рус драма театры** төзелеше тәмамланачак.

* Шәһәрнең 71 нче микрорайонында **«7 нче шәһәр поликлиникасы» ДАССУ** каршында **фельдшер-акушерлык пункты** төзү планлаштырыла.

* **«Чишмә» халыклар дуслыгы йортында** капиталь ремонт тәмамланачак.

* **8 мәктәптә азык-төлек блокларын** ремонтлау планлаштырыла.

* **Яр Чаллы йогышлы авырулар хастаханәсен** капиталь ремонтлау дәвам итәчәк.

* **«Яр буе» паркын** төзекләндерүне башлау планлаштырыла.

* **«Төзүче» спорт мәктәбендә** капиталь ремонт дәвам итәчәк .

* **«Ал җилкәннәр»** балалар сәламәтләндерү лагерена капиталь ремонт ясау буенча проект документларын эшләү алып барыла.

* **«КАМАЗ» стадионының** футбол кыры нигезенең өслеген алыштыру һәм ремонтлау эшләре башкарылачак.

* **5 нче шәһәр хастаханәсе** проектлана.

2022 елда да без сөекле һәм туган шәһәребезнең алга таба да чәчәк атуы хакына барлык планнарны һәм проектларны уңышлы тормышка ашырырбыз, дип ышанам.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт. Доклад тәмам.